**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422701 Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авылы, Зур Кызыл урамы, 113А йорт

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422701, Республика Татарстан, Высокогорский район,с. Высокая Гора, ул. Б. Красная, д. 113А

Тел./факс: +7(84365) 74-7-79 e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**19 декабрь 2025 ел** **№ 29**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2025 елның 16 маендагы 617/о номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында» боерыгын, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 мартындагы 120 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 31 гыйнварындагы 481 номерлы Биектау авыл җирлеге Советы карары;

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 июнендәге 677 номерлы Биектау авыл җирлеге Советы карары.

2. Әлеге карарны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында мәгълүматны актуальләштерү өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Биектау авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Салихзянов